**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИСАНСУПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСӘНСЕФ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423988, РТ Муслюмовский район д. Татарское Булярово. ул. Молодежная, д. 12
ИНН/КПП—1629003897/162901001 ОГРН – 1061687001221

**КАРАР № 16**

Татар Бүләр авылы 23 декабрь 2020

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 3 февралендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим районы Прокуроры протестын карау нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 3 февралендәге 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.1 пунктта «һәм адресация объектлары исемлеге» сүзләрен өстәргә;

- 1.5 пункттагы «адресация объектының идентификация элементлары» – «җир кишәрлекләре номерлары, башка адресация объектларының типлары һәм номерлары» редакциясендә бәян итәргә;

- 1.5 пунктка «адресация объекты булып торалар:

- бина (капиталь булмаган төзелештән тыш төзелеш ), шул исәптән төзелеш тәмамланмаган бина;

- корылма (капиталь булмаган корылмадан һәм линия объектыннан тыш) шул исәптән төзелеп бетмәгән төзелеш;

- җир кишәрлеге (торак пунктларның җирләренә карамаган һәм аларга капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен билгеләнмәгән җир кишәрлегеннән тыш);

- капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган бина» сүзләрен өстәргә.

1. - машина урыны (капиталь булмаган бинаның яисә корылманың бер өлеше булган машина урыныннан тыш).

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында muslumovo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә адресларны бирү,

үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын Татарстан Республикасы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Исәнсеф авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Ф.Т.Сахбутдинова**